ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Красавин ур., 40 нчы йорт, Яр Буе Моркваша авылы,
422594

Тел.: (84379) 3-16-47, факс: (84379) 3-16-47.

29.11.2025 № 4

На №______________ от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Урман Морквашы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2025 елның 20 марты №33-ФЗ «Бердәм хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 һәм 69 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст. нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны тотуның конкрет юнәлешләренә юнәлтүгә: -Урман Морквашы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга ризамы сез, дигән сорау буенча 2025 елның 29 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 61 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 32 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 32 кеше тавыш бирде

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны тотуның конкрет юнәлешләренә юнәлтүгә: -Урман Морквашы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга ризамы сез, дигән мәсьәлә буенча карарны таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов